**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы һәм 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-778 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан О.Д. Агаповны, Р.Ю. Беляковны, Р.Ш. Ганибаевны, Т.В. Забегинаны, Р.Р. Зариповны, И.И. Суфияровны, А.А. Фоминны чыгарырга;

б) Комитет составына кертергә:

аны Комитет рәисе итеп раслап, Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улын – Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасын, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасарын (килешү буенча);

Максимова Маргарита Николаевнаны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Социаль мәсьәләләр һәм хәйриячелек комиссиясе рәисен, Казан дәүләт медицина университетының социаль эш һәм шәфкать туташлары әзерләү буенча югары белем бирү факультеты деканын, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисен (килешү буенча);

Хисамиев Марат Рамил улын – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе

урынбасары – Департаментның Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгын;

Шиллер Дмитрий Августовичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Мәдәният комиссиясе рәисен, «Рус география җәмгыяте» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе рәисен (килешү буенча);

Шимина Нина Константиновнаны – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты рәисен (килешү буенча);

в) Комитет әгъзалары вазыйфаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.И. Бикиевның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университетының (Икътисад, идарә һәм хокук институты) беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча)»;

В.В. Вавиловның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасының лейкемия белән авыручы балаларга ярдәм итү буенча Анжела Вавилова исемендәге төбәк иҗтимагый хәйриячелек фонды идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

Т.Р. Кадыйровның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы советы рәисе, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

А.В. Королевның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының хокук мәсьәләләре һәм иҗтимагый контроль комиссиясе рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 21 июль
№ ПУ-432